БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
1 ноябрь 2018 ел № 150

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республика законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар **итте:**

1. Балтач район Советының 2013 елның 19 декабрендәге 199 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин

01.11.2018 елгы № 150
Татарстан Республикасы
Балтач район Советы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

**1.Нигезләмәнең 10-нчы пунктындагы 2-нче пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:**

“2) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы һәм автобиографияне билгеләнгән форма буенча язмача үзе һәм имзаланган анкета;".

**2.Нигезләмәнең 10-нчы пунктындагы 5-нче пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:**

“муниципаль хезмәткә урнашу елы алдындагы бер ел эчендә үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләрен һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;".

**3.Нигезләмәнең 10-нчы пунктындагы 6-нчы пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:**

"6) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыруның булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;".

**4.Нигезләмәнең 10-нчы пунктындагы 9-нчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"9) хәрби исәпкә алу документлары - запастагы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;".

**5.Нигезләмәнең 10-нчы пунктын түбәндәге эчтәлекле 10 -нчы пунктча белән тулыландырырга:**

«10) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы граждан һәркем файдалана алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны таныргa мөмкинлек бирүче белешмәләрне урнаштырган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтларның һәм (яисә) сайтлар сәхифәләренең адреслары турында хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге өч календарь ел өчен бирә.».

**6.Нигезләмәнең 15-нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«15) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын

тикшерү Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында»гы 2015 елның 2 февралендәге ПУ-71 номерлы Указы нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**7. Нигезләмәнең 16-нчы пунктында** «10» санын «30» санына алмаштырырга.